УДК 82.091

*Л.Р. Надыршина*

# ТУКАЙНЫҢ КАЗАНДАГЫ ЯКЫН ДАИРӘСЕ: ӘХМӘТГӘРӘЙ ҺӘМ ЗӘЙНӘП ХӘСӘНИЛӘР

В статье освещаются взаимоотношения классика татарской литературы Габдуллы Тукая с четой Ахметгараем и Зайнап Хасани, входящих в ближний круг поэта в Казани. Консолидировав вокруг издательства «Гасыр» и журнала «Аң» передовых представителей татарской молодежи, Ахметгарай Хасани стоял в авангарде общественно-культурных изменений начала XX века, а Зайнап, сподвижница и единомышленница своего супруга, сыграла неоспоримую роль в становлении и развитии журнала, занимавшего особое место в национальной печати начала XX века.

Автор статьи подчеркивает, что и Тукая, и чету Хасани объединяет идеал служения нации, что отражается в их художественной и общественной деятельности. Символичным является и сам факт, что на титульной странице самого первого номера журнала «Аң» был издан одноименный стих Тукая. В последующем стихи поэта публиковались практически в каждом выпуске журнала. На основе ряда фактических материалов в статье раскрывается роль Тукая в создании журнала и определении его основной концепции.

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, Ахметгарай Хасани, Зайнап Хасания, татарская литература, журнал «Аң» («Сознание»)

The article highlights the relationship between the classic of Tatar literature, Gabdulla Tukay, and the couple of Akhmetgaray and Zaynap Khasani, who were part of the poet’s inner circle in Kazan. By consolidating the leading representatives of the Tatar youth around the publishing house «Gasyr» and the magazine «An», Akhmetgaray Khasani was at the forefront of the socio-cultural changes of the early 20th century, while Zaynap, his wife’s companion and collaborator, played an undeniable role in the establishment and development of the magazine, which held a special place in the national press of the early 20th century.

The author of the article emphasizes that both Tukay and the Hasani family share the ideal of serving the nation, which is reflected in their artistic and social activities. It is also symbolic that the very first issue of the magazine «An» featured Tukay’s poem of the same name on its title page. Subsequently, the poet’s poems were published in almost every issue of the magazine. Based on a number of factual materials, the article reveals Tukay’s role in creating the magazine and defining its main concept.

**Keywords:** Gabdulla Tukay, Akhmetgarey Khasani, Zainap Khasania, Tatar literature, the magazine «Consciousness»

Һәркемгә мәгълүм: Г. Тукай Казанга 1907 елның октябрендә килә, һәм бу вакытта инде ул шагыйрь буларак формалашып җиткән, әдәби-иҗтимагый даирәдә исеме билгеле шәхес була. Уральскида якыннан аралашып киткән дусты – татар профессиональ театрына нигез салучы Габдулла Кариев истәлекләрендә әйтелгәнчә, Казанга

бару турында Тукай һәрвакыт хыяллана, андагы хәят үзенә шагыйрь буларак киң колач белән ачылырга этәргеч бирәчәгенә ышана: «Габдулла әфәнде шул вакытта ук Казанны бик яратып сөйли иде. Казанга барырга бик тели иде... Габдулла әфәнде Казанда бер эш кыла алачагына, үзенең шагыйрьлегенең дә анда танылачагына ышанадыр иде» [4: 97].

Тукайның бу ышаныч-өметләре, әле Казанга килгәнче үк, 1907 елның маенда «Фикер» газетасында һәм «әл-Гаср әл-җәдид» журналында басылып чыккан «Пар ат» шигырендә бик ачык күренә. Казанны милли кыйбла итеп изгеләштергән, татар дөньясының үзәге булган шушы каладан бөркелгән «хикмәт, мәгърифәт, нур»га омтылган шагыйрьнең өметләре, һичшиксез, аклана: монда ул чын мәгънәсендә татар рухи-мәдәни тормышының үзәгендә кайный башлый, һәрберсе меңләгән данәдә 32 китабы дөнья күрә, алдынгы татар газета-журналлары белән хезмәттәшлек итә, милли әдәбиятның иң күренекле вәкилләреннән берсенә әверелә, иҗаты халык арасында олы популярлык казана, алдынгы карашлы, милләткә хезмәттә беренче сафта торган зыялылар арасында фикердәшләр таба. «Казанда “кеше” бик күп, мин Уральскида үземә иптәш, утырдаш булырлык кешеләр таба алмый башлаган идем. Монда һәртөрле мәсләктә кеше бик күп, кайсы мәсләк кешеләре берлә күрешсәм дә, үземнән артык әллә ничә кеше таптым; шунлыктан тәрәккый итүем, гыйлем арттыруым өчен, мотлака (*әлбәттә, һичшиксез*), Казанда калырга кирәк дип карар бирдем» – Ш. Шәрәф үзенең истәлегендә Тукайның әнә шул сүзләрен теркәп калдырган [9: 288–289].

Тукайның Казандагы якын даирәсенә кергән Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев, Галиәсгар Камал, Вафа Бәхтияровлар янәшәсендә XX гасыр башы татар иҗтимагый хәятында күренекле урын тоткан, милли наширлек һәм матбугатны үстерүгә зур өлеш керткән Әхмәтгәрәй (1883–1933) һәм Зәйнәп (1886–1967) Хәсәниләр дә бар. 1903 елда гаилә корып, көндәлек тормышта да, милләткә хезмәттә дә бер-берсенә фикердәш һәм терәк булган бу фидакяр шәхесләр икесе дә чыгышлары белән Әтнә төбәгеннән булган алдынгы карашлы бай сәүдәгәрләр нәселеннән. Сибгатулла Гайнулла улы гаиләсендә дөньяга килгән Әхмәтгәрәй әтиләре тырышлыгы белән өйләренә килеп укыткан мөгаллимнәрдән белем алып, соңрак «Мөхәммәдия»дә укып, рус, гарәп, төрек, алман, француз телләрен белгән, Шәрык, рус, Европа мәдәниятләре буенча тирән белемле шәхес булып җитешә. Дистәләрчә мәчет төзеткән, туган җирендә (хәзерге Әтнә районы Түбән Көек авылында) ир-егетләр һәм хатын-кызлар өчен мәдрәсәләр салдырган беренче гильдия сәүдәгәр Ногман Габделкәримов кызы Зәйнәп Хәсәния дә, «Халидия» мәдрәсәсеннән тыш, өйдә рус гимназиясе программасы буенча белем ала, рус һәм чит ил әдәбиятларын яхшы белә. Белемле, аңлы, киң карашлы, тирән фикерле Зәйнәп ханым милли идеаллар белән янып яшәгән Әхмәтгәрәй Хәсәнинең төп фикердәше, таянычы, ярдәмчесе була.

Шушы ике зыялы фидакяр XX гасыр башы милли-мәдәни яшәешендә зур роль уйнаган, татар халкын югары сыйфатлы, тирән эчтәлекле китаплар белән тәэмин иткән, ахыр килеп, алдынгы карашлы татар иҗтимагый-сәяси һәм әдәби эшлеклеләрен үз тирәсендә берләштергән үзәккә әйләнеп киткән «Гасыр» басмаханәсенә нигез сала. 1907 елда башлап җибәрелгән бу эшләре турында Зәйнәп Хәсәния язучы М. Мәһдиевкә болай дип сөйләгән була: «Әти-әни язу эшенә каршы килделәр. Җитмәгән сумманы минем бриллиант, энҗе, йөзекләрне сатып әзерләдек. Башта китаплар бастырдык» [5: 196]. Әнә шулай Әхмәтгәрәй һәм Зәйнәп Хәсәни үзләренең бөтен малын китап нәшер итү эшен нигезләүгә тоталар. Шуннан соң инде, 1908 елда, Габдрахман Рәхмәтуллин белән бергә, Әхмәтгәрәй «Гасыр» дип исемләнгән басмаханә оештыра һәм китап кибете ачуга да рөхсәт ала. 1909 елның 1 гыйнварыннан инде Евангелистовская (хәзер Татарстан) урамындагы бертуган Ибраһимовлар йортында бу китап кибете эшли дә башлый. Бу хакта «Әлислах» газетасының 1909 елгы 20 гыйнвар санында басылган игълан тексты сөйли:

«“Гасыр” көтепханәсе ачылды! Казанда, Евангелистовский урамында, Ибраһимовлар йортында.

Хөрмәтле укучылар!

Без, ике сәнәгә (*елга*) якын дәвам иткән нәшрият эшемезне тагын да мөкәммәл (*камилләшкән*) сурәттә тәрәккый иттерергә иҗтиһад итеп (*тырышып*), «Гасыр» көтепханәсе исемендә бер китап мәгазәсе ачарга мөвәффәкъ улдык (*ният кылдык*). Нәшриятымызга матди вә мәгънәви ярдәмче булган мөхтәрәм укучыларга тәшәккер (*рәхмәт*) итеп, көтепханәмезнең ачылганын белдерәмез.

Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкәсе».

«Гасыр» басмаханәсе һәм шул исемдәге көтепханә ачылу белән бәйле башка документлар бүгенге көндә Татарстан Дәүләт архивында саклана, һәм алар «Җыен» фонды тарафыннан «Шәхесләребез» сериясендә Әхмәтгәрәй Хәсәнигә багышлап чыгарылган фәнни-популяр җыентыкта (төзүчеләре Д.Ф. Заһидуллина, А.Д. Батталова, Л.Н. Йөзмөхәммәтова) киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителделәр [1: 240–241].

«Гасыр» бөтен көчен татар әдәбиятының иң камил үрнәкләрен бастырып чыгаруга һәм пропагандалауга, шулай ук татар укучысын рус һәм чит ил әдәбияты үрнәкләре белән таныштыруга куя, шулай ук балалар өчен китаплар да нәшер итеlә. Анда XX йөз башы татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләре: Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Г. Рәхим һ. б. ның әсәрләре, башка әдәбиятлардан тәрҗемәләр, сүзлекләр дөнья күрә, һәм алар полиграфик яктан да бик югары сыйфатлы булалар (гомумән, басмаларның һәрьяклап сыйфатлы булуына Әхмәтгәрәй Хәсәни аерым игътибар бирә). Әхмәтгәрәй Хәсәни эшчәнлеген җентекле өйрәнгән Л. Йөзмөхәммәтова нәшриятта басмаларның билгеле бер серияләргә берләштерелүен күрсәтә. Мәсәлән, «Театр мәҗмугасы» сериясеннән Г. Ильяс (Ә. Хәсәнинең

псевдонимы), С. Рәмиев, Гали Рөстәм (Г. Рәхмәтуллинның псевдонимы), Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Кариев, И. Казаков, А.С. Пушкин, Ф. Шиллер пьесалары басыла; «Хыйффәте сыйххәт» сериясендә медицина белеме буенча рус галимнәренең хезмәтләре тәрҗемә ителә [3: 235].

Г. Тукайның 1909 елда дөнья күргән «Габдулла Тукаев диваны» дип аталган әсәрләр җыентыгы да нәкъ менә шушы нәшриятта әзерләп чыгарыла. «Гасыр»да шагыйрьнең 1912 ел март-апрельләрендә ясалган фоторәсеменең почта открыткасы рәвешендә басылуы да билгеле. Шул фотооткрыткаларның «Мөхтәрәм Әхмәтгәрәй вә Габдрахман әфәнделәрә ядкәрем. 5 август, 1912 ел. Г. Тукай» дигән автографлысы бүгенге көндә Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана (9 ф., 3 тасв., 49 сакл. бер).

«Хәтер түрендә» дип аталган истәлек язмасында Зәйнәп Хәсәния түбәндәгеләрне яза: «“Гасыр” нәшриятының хәзерге Татарстан урамында ике бүлмәсе бар иде. Эчкәреге бүлмә – редакция, эш бүлмәсе, алгы бүлмә – китап кибете. Менә шул эш бүлмәсе һәрвакыт гөр килеп тора иде. Анда Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Х. Ямашев, Г. Коләхмәтов, Г. Рәхим һ. б. бик еш булалар иде. Алар һәр әдәби яңалык турында сөйләшәләр, үзләренең яңа әсәрләрен укып фикер алышалар иде» [8: 16]. Әнә шулай «Гасыр» басмаханәсе алдынгы фикерле татар зыялыларын бергә туплаган үзәк булып та китә. Нәкъ шул елларда Казанга күчеп килгән Тукай да тиз арада бу бүлмәдә көтеп алынган кунакка әйләнә. Тукай белән Хәсәниләрнең дус-фикердәшкә әйләнеп китүләрендә «Шәрык клубы»ның да роле зур, әлбәттә. Идарә әгъзасы буларак, Әхмәтгәрәй Хәсәни клуб эшчәнлегендә актив катнаша, Зәйнәп Хәсәниянең дә анда төрле чараларны оештыруда башлап йөрүе билгеле, ә инде Тукай клубтагы әдәби-музыкаль кичәләрне еш тамаша кыла һәм үзе дә бу чараларда чыгыш ясый. Әйтик, атаклы «Халык әдәбияты» дигән лекциясен шагыйрь шушы клубта укый (1910 ел, 15 май).

Үзенчәлекле милли-иҗтимагый үзәк булып киткән, әдәби-мәдәни тормыш кайнап торган «Шәрык клубы»на жандармерия тиз арада үзенең игътибарын юнәлтә. Биредә татар яшьләренең җыелуы, сәяси түгәрәк оештыруы турында нәтиҗәләр чыгарыла. Жандармериягә киткән язмаларның берсендә Әхмәтгәрәй Хәсәни катнашкан түгәрәк хакында да хәбәр бар. Бу турыда Г. Мансуровның 1927 елда дөнья күргән «Татар провокаторлары» китабында мәгълүмат табарга мөмкин. Түгәрәк әгъзалары татар әдәбиятын үстерү максаты белән берләшәләр. Г. Мансуров китабында хәбәр ителгәнчә, 1912 елның 26 июлендә түгәрәкнең чираттагы җыены Хәсәниләр дачасында үтә. Анда Әхмәтгәрәй һәм Габделбари Хәсәниләр, Ф. Туктаров, Г. Гыйсмәтуллин, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Коләхмәтов, И. Аитов, Г. Шәрәф, Г. Ибраһимов, Г. Кәрам катнаша, һәм алар «Аң» журналын чыгару турында карар кабул итәләр [1: 147–151].

Әнә шулай уртак максатлар Хәсәниләр гаиләсен Тукай белән якынайта. Казанда яшәү дәверендә татар байлары белән аралашудан читләшкән, ә инде хатын-кызлар җәмгыятеннән бөтенләй диярлек ерак торган шагыйрь Хәсәниләр белән якыннан аралаша, аларда кунакта булгалый. Зәйнәп Хәсәни үзенең истәлегендә Тукайның бу очрашуларда тапкыр телле, акыллы, әмма гади, тыйнак һәм ягымлы кеше буларак ачылуын искәртә. Очрашуларның берсе турында Зәйнәп Хәсәния болай дип яза: «Г. Тукай үзенә якын, күптәнге танышлары белән тартынмыйча ачык сөйләшсә дә, чит кешеләр белән, бигрәк тә хатын-кызлар белән бик оялып, тартынып кына сөйләшә, яки бөтенләй сөйләшми иде. Бервакыт хәтеремдә, безгә кунакка килгәч, чәй янында ул үзен бик иркен тотып сөйләшеп утырды. Бу чәй табыны дачада, террасада керосин лампасы яктысында гына үтте. Мөгаен, аңа бик якты булмаганлыктан, ул үзен иркенрәк тоткандыр. Шунда Ф. Әмирхан сүз арасында Г. Тукайга бер гарәпчә шигырь укыды. Шигырьнең төп фикере болай иде: “Кеше дус сайлаганда гакыллырак, тотнаклырак кешене сайларга тиеш, чөнки күп вакытта дус-дуска иярүчән була, шуңа карап, кешенең кемлегенә бәя бирәләр”. Г. Тукай шул минутта ук Ф. Әмирханга шулай ук гарәпчә шигырь укып җавап бирде. Тукай укыган шигырьнең мәгънәсе менә нинди иде: “Берәүнең яман яклары күп булыр, шуңа карап, аның дустын да яманларга кирәкмени!!” Г. Тукай шулай тиз генә уйлап, шигырь белән җавап бирүчән, тапкыр кеше иде» [8: 16].

«Аң» журналы нәшер ителә башлау Хәсәниләр белән Тукайны тагын да якынайта. Тәүге санында наширләр тарафыннан «милли әдәбиятымыздан шигырьләр, хикәяләр вә романлар дәрҗ ителеп, рус әдәбиятына вә чит мәмләкәт әдәбиятына да тиешлесенчә урын биреләчәкдер; әдәбияттан башка тәнкыйди, сәяси-иҗтимагый, икътисади, фәнни, сәнәгый, тыйбби (*медицина*) вә әхлакый мәкаләләргә дә урын бирелеп, көлке вә һәҗүви кыйсем (*сатирик бүлек*) дә кертеләчәктер; ачык татар телендә, яхшы кәгазьдә, нәфис зурлыкта, яңа чыгарылган матур хәрефләр белән басылачак» дип сыйфатланган журнал үз чоры өчен генә түгел, бүгенге көндә дә актуаль булган проблемаларны күтәрә торган мәкаләләрне, вакыт чиген үткән әдәби әсәрләрне укучыга тәкъдим итә, гомумән, яңалык, әдәби тәҗрибә мәйданы булып китә. Д.Ф. Заһидуллина билгеләвенчә, «Аң» битләрендә милләтнең иртәгәсе, киләчәге турында сөйләшү бара, иҗтимагый-мәдәни яңарышның милли үсеш-үзгәреш ихтыяҗына буйсындырылырга тиешлеге ачыклана. Моның теоретик нигезләре күзаллана [2: 18]. Әхмәтгәрәй журналны бастыру, кәгазь, буяу юнәтү кебек оештыру эшләре белән йөргән вакытларда басманы әзерләү, килгән материалларны редакцияләү Зәйнәп җилкәсендә була.

Журналның төп юнәлешен билгеләүдә Тукайның роле зур була, «Аң» дигән исемне дә басмага ул бирә. Бу хакта Әхмәтгәрәй Хәсәни үзенең Тукай вафатына бәйле истәлегендә язып үтә, аны «“Аң” журналының исем кушучысы, нигез салучыларыннан берсе, иң эшлекле


آڭ

ايكى آطنەدە بر چيقا طورغان ادبى، فنى، سياسى، اجتماعى رسملى ژورنال.

آڭ.

بز «بيشنچى» يلنى بر كوننى اوياندق طاڭ بلن،
اشكه دعوت ايتدى بزنى كيفر ايزگى نام بلن،
اشكه باشور چاق جيتب، يەمسز اوزون توِن اوتكان،
كوز آچوب، بلدك بز ئولچەب كوكدەگى «وايان» بلن.

—

بولسەدە اول چاقدە بزدە كورسز ايمان، صاف كوڭل،
كوز همان بولدى ئرزلى، بوزدە صاف هم پاك توگل،
شول سببلى دوستنى، دشماننى درسته فرق ايتميچه،
كوب صاناشدردق رذيل شيطاننى چن انسان بلن.

—

ئەڭگى، ميڭگى باش بلوندە اشلدك، بولسون قبول،
جبرائيل آچقاى اول اشلرگه سيگز قات كوككه يول،
اوندى ايندى دوستلرم اول اوتكان اش نى بولسه اول
ايندى اشليك صاف آچق كوزلر بلن، چن «آڭ» بلن.

ع. توقايف.

«Аң» журналының беренче саны

мөхәррире һәм бөтен татарның мактанычы булган иң кадерле шагыйре», дип зурлый [7: 177].

Журналның беренче саны 1912 елның 15 декабрендә дөнья күрә, һәм ул Тукайның «Аң» шигыре белән ачыла. Шигырендә шагыйрь журналның милләтне йокыдан уятачак, алгарышка илтәчәк көч булуына ышаныч белдерә, шатланып, киләчәккә өметләр баглый. Тукай вафатына кадәр «Аң»ның берничә саны гына дөнья күреп өлгерә, һәм аларның һәрберсендә шагыйрьнең әсәрләре урын ала. Клячкин шифаханәсенә кергәч тә, Тукай Хәсәниләр белән журнал турында хатлар алыша, шифаханәдән язылган иң соңгы хаты да нәкъ менә Зәйнәп Хәсәнигә була:

«Мөхтәрәмә Зәйнәп ханым!


8 нче санга бар кадәремне җибәрдем. Беренче корректурын үземә күрсәтсәңез икән. Аннан соң шушы язылган микъдар шигырьнең һәммәсе бер номерга кереп бетсә иде. Шулай булганда, ул шактый көч булырлык. Хәер, «Толстой сүзләре»нең бер-икесен синзур бозар кеби сизәм. Ул вакыт һәммәсенең басылуы мәҗбүри үк булыр» [6: 241].

Шагыйрь гомеренең ахыргы сәгатьләрен Әхмәтгәрәй Хәсәни белән үткәрә. Менә-менә өзелергә торган Тукай, Әхмәтгәрәйнең хәл соравына җавап бирерлек хәле булмаса да, «Аң»да басылачак шигырьләренең соңгы корректурасы хакында сорарга үзендә көч таба. «Габдулла әфәнде “Аң”да бастырган шигырьләренең соңгы корректураларын үзе караучан иде. Бу юлы да 8 нче сан “Аң”да дәрҗ ителгән *(теркәлгән)* өч шигыренең матбага хаталарын тасхих итәргә *(редакцияләргә)* теләп соравы иде.

Шул хәтле авыру, авыр хәлдә яткан Габдулла әфәнденең бу соравыннан мин бик тәэсирләндем, аңар ни дип җавап бирергә бераз аптырап та тордым. Ул сораган корректура ул вакыт минем янында булса да, бирсәң, я шул минутта ук торып төзәтә башлар да, үзенең сәламәтлегенә тагын да зарар итәр дип, бирмәскә уйладым.

– Корректура иртәгә була, – дидем.

Ул шуның белән бетте. Габдулла әфәнде, минем җавабыма канәгатьләнеп, сөкүт итте *(тын калды)*» [7: 177].


محترمه زینب خانم!
٨ نچی صانی غه بار قدر منی جیبه‌ردم.
برنچی کاررکتورنی اوز یمه کورسه‌تسه‌گز
ایکان. آندن صونگ شونی یازلغان
مقدار شعرنگ همه‌سی برنومیرگه کرب بتسه
ایدی. شولای بولغانده اول شاقتلی کوچ بولور
لق. خیر، „طالستوی سوزلری" نی برایکیسن
سیزنگ بوزارکیز سیزده‌م. اول وقت همه
سین باصلووی مجبوری اولوق بولور.
ع. توقایف
٢٨ مارت ١٩١٣.

Г. Тукайның З. Хәсәниягә язган хаты. 1913 ел, 28 март

Тукай вафат булгач та, Хәсәниләр «Аң» битләрендә аның иҗатына зур урын бирәләр, апрель айларында шагыйрьгә багышланган махсус сан чыгаралар яисә аңа сәхифә багышлыйлар. Һәрвакыт җентекле цензура контроле астында яшәгән «Гасыр» басмаханәсе һәм «Аң» журналы Октябрь вакыйгаларыннан соң ябыла, Әхмәтгәрәй, типографиясен дәүләткә тапшырып, 1926 елда «Яңа китап» дигән башка басмаханә оештырып карый, әмма ул да өч елдан эшен туктата. Шушы басмаханәдәге эшчәнлеген сәбәп итеп, ялган гаеп белән Әхмәтгәрәй 1931 елда кулга алына, Беломор каналын төзергә җибәрелә, 1933 елда тиф авыруыннан үлеп китә. Кабере билгесез.

Әхмәтгәрәйнең 1913 елда типография эшләре белән Европага сәфәре вакытында Зәйнәпкә язган хатларының берсендә шундый юллар бар: «Күп булса бер атнадан соң ватаным Русия туфрагына аяк басармын, төп нигезем Казанда булырмын. Ватанымга кайтып җитү фикере илә сәяхәтемнең бу соңгы атнасында мин шатланам. ... Мин Ватанга якынлашкан саен шатланам. Чөнки анда син бар; анда Гали вә Әминәм, анда «Гасыр»ым вә кәримем бар, анда ата-анам вә борадәрем бар! Анда кардәшләрем вә якыннарым бар. Яуропаның бөтен гаҗәсәбәте, бөтен мәдәнияте вә дәүләте мине хәзер әүвәлге кеби кызыксындырмый, минем исемне китерми. Мин Ватаным белән анларны алыштырмыйм. Минем Ватанымда ни теләсәм – шул бар. ...Кайтам! Бөтен Яуропаның дәүләт вә сәгадәтен ташлыйм да Ватаныма кайтам» [1: 292]. Ватанын, газиз җирен шул дәрәҗәдә сөйгән Әхмәтгәрәй Хрущев «җепшеклегенә» кадәр халык дошманнары исемлегендә йөри, фәкать 1959 елда гына Зәйнәп Хәсәния иренең исемен аклатуга ирешә. Тукай белән аралашкан, ХХ гасыр башы татар матбугатын һәм китап бастыру эшен үстерүдә ире белән иңгә-иң куеп хезмәт иткән Зәйнәп ханым – аңлы, зыялы, олы йөрәкле шәхес – гомеренең азагынача ире һәм замандашлары турындагы тарихи хәтерне сакларга тырыша, һәрвакыт әдәбият-сәнгать әһелләре белән аралашып тора, истәлекләре, фикерләре белән уртаклаша. Дүрт

балаларының да гомерләре иртә өзелеп, нәсел дәвамчылары калмаса да, Әхмәтгәрәйнең ир туганы Габделбариның кызы Рөгъдә ханымда Зәйнәп Хәсәния архивыннан материаллар сакланып кала. Алар күренекле әдәбият галиме Д. Заһидуллина һәм Хәсәниләр эшчәнлеген махсус өйрәнгән Л. Йөзмөхәммәтова тарафыннан төзелгән фәнни-популяр җыентыкта («Шәхесләребез» сериясеннән) туплап бирелә. Рөгъдә ханым тапшырган Хәсәниләрнең гаилә альбомы бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать инстиутының Язма мирас үзәгендә саклана.

Тукай Казанда шәхес һәм шагыйрь буларак үзгә бер колачлылык белән үсеп китә, әдәби офыгы һәм иҗтимагый карашлары тагын да киңәя, дибез икән, һичшиксез, монда аның Казандагы якын даирәсе – бер төркем татар зыялыларының роле дә зур. XX йөз башы милли-мәдәни алгарыш юлын сызып баручылардан булган Әхмәтгәрәй һәм Зәйнәп Хәсәниләр – шушы даирәнең күренекле вәкилләре.

**Әдәбият**


1. Әхмәтгәрәй Хәсәни: фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2011. 408 б.
2. *Заһидуллина Д.Ф.* XX йөз башы татар яңарышының фикри лидеры // Әхмәтгәрәй Хәсәни: фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2011. Б. 9–25.
3. *Йөзмөхәммәтова Л.* XX йөз башы татар мәдәни тормышында Әхмәтгәрәй Хәсәни // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2009. № 2. Б. 234–236.
4. *Кариев Г.* Габдулла Тукаевның Уральскида тормышы // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар / Төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. Б. 96–97.
5. *Мәһдиев М.* Мөхтәрәмә Зәйнәп ханым... // Әхмәтгәрәй Хәсәни: Фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2011. Б. 195–198.
6. *Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 5 т.: мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 415 б.
7. *Хәсәни Ә.* Тукаев үлем көткәндә // Аң. 1913. № 10. Б. 176–177.
8. *Хәсәния З.* Хәтер түрендә // Азат хатын. 1967. № 4. Б. 16–17.
9. *Шәрәф Г.* Тукай турында истә калганнар // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015.



***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Надыршина Лейсан Радифовна,***
*доктор филологических наук, старший научный сотрудник Центра письменного наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*leysan_tatar@mail.ru*